

2020 елдан илдә Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча эшләнгән «Авыл территорияләрен комплекслы vстерv» дәvләт программасын гамәлгә ашыру башланды. Анда катнашу аркасында Мордовия республикасы Рузаевка районы да сизелерлек vзгәрә. Алга таба авылларда нинди vзгәрешләр булачагы турында Рузаевка районы башлыгынын тозелеш һәм перспективалы vсеш буенча урынбасары (исполняющий обязанности заместителя главы Рузаевского МР по строительству и перспективному развитию) вазыйфаларын башкаручы Руслан Ринат улы Ларин белән «Рузаевские новости»дан Лия Савельева әнгәмә корды. *- Руслан Ринатович, эйтегез эле, узган ел Рузаевка районында нинди грантлар тормышка ашырылды?*

- «Авыл территорияләрен комплекслы vстерv» дәvләт программасы кысаларында 2022 елда районнын авыл жирлекләре тарафыннан биш грант унышлы гамәлгә ашырылды. Татар Пешләсендә без яна спорт мәйданчыгы тозедек. Красный Клин авылында йомшак япма белән балалар мәйданчыгы жиһазландырылды. Сузгарье, Мордва Пишлясы һәм Аргамаковта без уен һәм спорт зоналары белән типовой проектны гамәлгә ашырдык.

*- Быел ничэ грантны тормышка ашыру планлаштырыла?*

- 2023 елда безгә зур кvләмдә эш башкарырга туры киләчәк. Без «Авыл территорияләрен комплекслы vстерv» программасы буенча 8 грант, шулай ук «Авыл территорияләренен хәзерге кыяфәте» подпрограммасынын 4 проектын гамәлгә ашырырга ниятлибез. Рузаевка районында ял итv, спорт белән шогыльләнv, мәдәни-массакvләм чаралар vткәрv очен зоналар каралган яна локацияләр булдыруга басым ясала. Уен һәм спорт мәйданчыклары Хованщинада, Инсар-Акшинода, Шишкеевода, Левжада һәм Новая Муравьевкакада барлыкка киләчәкләр. Левженский бистәсендә жәмәгать территориясе тирәсендә койма урнаштырылачак, әмма, моннан тыш, Үзәк урамындагы 2, 3 һәм 4 нче йортлар янында тротуарлар салачакбыз. Яковщина авылында Знаменский чиркәвен торгызу дәвам итә, шуна кvрә анын тирәсендә без юлларны һәм тротуарларны янартырга планлаштырабыз.

*- Ин мөһим vзгэртеп корулар Красносельцовский авыл жирлегендэ планлаштырылган. Бу турыда сөйлэгез?*

- Беренчедән, суvткәргеч ремонтлау, икенчедән, Мәдәният йорты тозv. Балалар

бакчасын ремонтлау да моһим булып кала. Моннан тыш, без узган ел тозелгән Үзәк мәйданда бушлай Wi-Fi зонасы ясарга уйлыйбыз. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, балалар бакчасын ремонтлау бара, шулай ук яна Мәдәният йорты тозелеше дә башланды. Красносельцово авылы бик тиз vсә, шуна кvрә кvп олкәләрдә янартуны таләп итә. Клубнын иске бинасы авария хәлендә булганлыктан, анда шогыльләнv момкин булмаганлыктан, тvгәрәкләр һәм секцияләр башка урынга кvчерелде. Әмма авылда мәдәният учреждениесе бик кирәк һәм анда хезмәткәрләр штаты да шактый зур булганлыктан, без иске корылманы сvтеп, яна заманча бина тозv турында Карар кабул иттек. Илнен авыл хужалыгы министрлыгына мондый кирәкле һәм вакытында программа очен рәхмәт белдерәсем килә.

*- Ринат улы Руслан, районыбызнын авыл жирлеклэрендэ төзелеш өчен участоклар никадэр кирэк?*

- Алар гражданнар соравы буенча тозелә. Жир кодексына быел март аенда vзгәрешләр кертелде, хәзер жир кишәрлекләрен бирv һәм сату электрон мәйданчыкларда алып барыла. Красносельцовский һәм Приреченский авыл жирлекләре ин кирәкле участоклар булып тора. Аларнын чикләрендә мондый участокларны формалаштыру очен урыннар калмаган диярлек. Калганнарда исә, сорау буенча, моны эшләv бик реаль. Мәсәлән, Плодопитомник поселогы динамик vсештә булган муниципаль берәмлек. Биредә мәктәп, балалар бакчасы, клуб, оч кибет урнашкан. Рузаевкага кадәр ара 11 км тәшкил итә, Саранскига кадәр 26 км. Ускляй елгасы янындагы урманчык янында торак тозелеш очен жир участоклары формалаша. Аларнын һәрберсенен бәясе, мәйданы якынча 1500 кв. м, 170 мен сум. Шулай ук Сузгарьеда участоклар бар. Алар урман массивы һәм сулык янында урнашкан; аларнын мәйданы 12 000 кв. м. участокларнын бәясе 154 000 мен сум. Хәзерге вакытта Рузаевка янындагы Левжа авылында жир участокларын арендага бирv буенча сату процедурасы уза. Мондый жир кишәрлекләренен аренданын башлангыч бәясе елына 17 мен сум.

Болдово авыл жирлегендә, анда югары хезмәт хакы белән «Исток» алдынгы авыл хужалыгы предприятиесе vз эшчәнлеген алып бара, торак йортлар тозv очен Никольская урамында 1500 кв.м мәйданлы жир участоклары формалаштырыла.

**Наилә НАСЫРОВА** *эзерлэде*